ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.11.2020 п.г.т.Алексеевское № 450

**«Алексеевск муниципаль районында**
**кече һәм урта эшкуарлык субъектларына**
**мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча**
**эш төркеме төзү турында» 2020 елның**
**19 мартындагы 109 номерлы башкарма**
**комитет карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Алексеевск муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү һәм Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының җирле үзидарә органнары, башка органнар һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында

**карар бирәм**:

1. Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 19 мартындагы 109 номерлы карарына 1 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

- «Кадыйров Н.К. - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, эш төркеме җитәкчесе» сүзләрен «Гайнуллин О.А. - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, эш төркеме җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга,
- «Гайсин М.Р. - Алексеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, эш төркеме җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «Язынин Р.С. - Алексеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, эш төркеме җитәкчесе урынбасары» сүзләренә алмаштырырга,
- «Булыгина Е.К. - Алексеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы баш белгече, эш төркеме секретаре» сүзләрен «Плотникова Е.П. - Алексеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы баш белгече, эш төркеме секретаре» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет hppt://alekseevskiy.tatarstan.ru мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А.Гайнуллин**